**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 13 февралендәге 365 номерлы карары**

**2025 елда социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар арасында Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсын уздыру турында**

Казан шәһәре кешеләренә ярдәм итүгә һәм тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның социаль әһәмияткә ия эшчәнлеген тану һәм аларга булышлык итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар арасында Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсын уздыру турында Нигезләмәне расларга (1 номерлы кушымта).

2. Социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар арасында Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсы җиңүчесен һәм конкурс призерларын билгеләү буенча конкурс комиссиясе составын әлеге карарның 2 номерлы кушымтасы нигезендә расларга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратын (Б.Р.Алиев) социаль юнәлештәге коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар арасында Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсын оештыручы булып тора дип билгеләргә.

4. Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсын оештыру, тантаналы чаралар үткәрү һәм акчалата призлар бирү буенча чыгымнарны 1 500,0 мең сум күләмендә Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының 2025 елга бюджет язмасы чикләрендә башкарырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевкә йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 13 февралендәге
365 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар арасында Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсы турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсы (алга таба – Конкурс) турындагы әлеге Нигезләмә Казан шәһәрендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруны башкара торган социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар арасында Конкурсны уздыру максатларын, шартларын, тәртибен билгели.

## II. Максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның социаль әһәмияткә ия эшчәнлеген тану һәм аларга булышлык итү, Казан шәһәрендә кешеләргә ярдәм итүгә һәм тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән социаль әһәмияттәге проектларны популярлаштыру максатыннан уздырыла.

2.2. Конкурсның бурычлары:

- Социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның эшчәнлеген җәмәгатьчелекнең тануы һәм игътибарын җәлеп итү;
- хәйриячелек культурасын популярлаштыру;
- мөһим гуманитар проблемаларны хәл итүгә аерым өлеш керткән оешмаларны бүләкләү;
- иң яхшы социаль практикаларга ярдәм күрсәтү һәм аларны тиражлау;
- Казан шәһәренең социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларын берләштерү.

## III. Катнашучыларның категорияләре һәм катнашу шартлары

3.1. Конкурста 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерцияле булмаган оешмалар турында»гы федераль законда билгеләнгән коммерцияле булмаган оешма категориясенә кертү критерийларына туры килгән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып барган дәүләт яисә муниципаль учреждениеләр булмаган социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар катнаша ала.

3.2. Конкурста муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары, коммерция һәм дини оешмалар катнаша алмый.

3.3. Премия 2024 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә кешеләргә ярдәм итүгә һәм тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга түбәндәге юнәлешләр буенча бирелә:

- гражданнарның социаль яктан аеруча якланмаган категорияләренең иминлеген арттыру, кешеләргә социаль ярдәм күрсәтү, хайваннарны яклау, әйләнә-тирә мохитне саклау;

- психик һәм физик сәламәтлекне саклау, донорлык, сәламәтлек саклауны үстерү, физик культураны һәм спортны, шулай ук сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен үстерү;

- мәдәни кыйммәтләрне һәм традицияләрне саклау, патриотизмны үстерү, тарихи хәтерне саклап калу, талантларны ачу һәм шәхес үсеше, мәгарифне үстерү.

## IV. Гаризалар бирү тәртибе һәм формасы

4.1. Конкурста катнашу өчен премиягә дәгъва кылучылар түбәндәге документларны тапшыра:

- мөрәҗәгать итүче оешма турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгы булган гариза, шулай ук оешма турында белешмәләр (оешманың мәгълүмати картасы), проект турында белешмәләр (проектның мәгълүмати картасы). Гаризаның формасы әлеге Нигезләмәгә 1 номерлы кушымтада бирелгән (аңа беркетелә торган документларның формалары – гаризага 1, 2, 3 номерлы кушымталарда);

- социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешма уставының күчермәсе;

- әгәр күрсәтелгән документларга гариза бирүче оешма исеменнән аның гамәлгә кую документлары нигезендә ышанычнамәсез эш итәргә хокукы булмаган зат имза куйса (таныкласа), әлеге пунктта күрсәтелгән документларга имза кую (таныклау) өчен затның вәкаләтләрен раслый торган ышанычнамә яисә башка документ.

- гариза бирүче оешманың законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычы булмавын раслый торган документ, шулай ук мөрәҗәгать итүче оешманың үзгәртеп кору, ябылу стадиясендә булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, конкурста катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган булуын раслый торган документлар;

- юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (документ коммерцияле булмаган оешма тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырыла яисә ведомствоара хезмәттәшлек барышында вәкаләтле орган белгече тарафыннан соратып алына).

4.2. Барлык материаллар да рус телендә Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе электрон почтасына social.kzn@tatar.ru. электрон рәвештә тапшырыла. Хат темасында социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешма исемен күрсәтергә кирәк.

4.3. Конкурста катнашуга гаризаны кире кагу өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- премиягә дәгъва кылучының әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

- премиягә дәгъва кылучы тарафыннан тапшырылган гаризаның һәм документларның әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктчасында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- премиягә дәгъва кылучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турында мәгълүматның дөрес булмавы;

- премиягә дәгъва кылучы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 6.1 пунктчасында билгеләнгән вакыт чикләреннән соң гариза бирү;

## V. Конкурс комиссиясен төзү һәм эшләү тәртибе

5.1. Эшләрне карау өчен Казан шәһәре Башкарма комитеты, Казан шәһәренең коммерциягә нигезләнмәгән оешмалары вәкилләреннән конкурс комиссиясе төзелә.

5.2. Конкурс комиссиясе составына комиссия рәисе, секретарь һәм 12 комиссия әгъзасы керә.

5.2.1. Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, шулай ук комиссия утырышларын үткәрү өчен җавап бирә.

5.2.2. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары конкурс комиссиясе рәисе булмаган чорда аның вазифаларын башкара.

5.2.3. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе эшен оештыруны, шул исәптән гаризалар исемлеген формалаштыруны, карарлар төзүне, комиссия утырышы беркетмәсен алып баруны тәэмин итә.

5.3. Конкурс комиссиясе составы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.4. Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итүне Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе башкара.

5.5. Конкурста катнашучыларга бәя бирү өчен Конкурс комиссиясе:

- премиягә дәгъва кылучы турында мәгълүмат булган анкеталарны карап тикшерә;
- һәр катнашучының эшен гадел бәяли;
- һәр катнашучының рейтингыннан чыгып Конкурска йомгак ясый.

5.6. Конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны ачыклаганда тавышлар саны тигез булса, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып санала.

5.7. Конкурс комиссиясе үз көче белән һәм үз вәкаләтләре кысаларында тапшырылган материаллардагы мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерә. Конкурста катнашу өчен бирелгән гаризада ялган яки дөрес булмаган белешмәләр, шулай ук гамәлдәге законнарга каршы килә торган мәгълүмат ачыкланган очракта, мондый гариза карап тикшерелми.

5.8. Конкурс комиссиясе әгъзасының җиңүчене билгеләгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, ул, конкурс комиссиясе утырышы башланганчы бу хакта конкурс комиссиясе рәисенә хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы конкурс комиссиясе утырышында катнашмый.

5.9. Конкурс комиссиясе утырышы, анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала.

5.10. Конкурс комиссиясе карары катгый һәм үзгәртелми.

## VI. Конкурсны уздыру һәм конкурста җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

6.1. Премиягә дәгъва кылучылар гаризаларны 2025 елның 27 февраленнән 30 мартына кадәр әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән номинацияләр нигезендә бирә.

6.2. Комиссия документларны кабул итү тәмамланган көннән соң, ике эш көне эчендә премиягә дәгъва кылучыларның гаризаларын аларны конкурста катнашучылар дип тану максатыннан карап тикшерә.

Әлеге Нигезләмәнең 4.3 бүлегендә күрсәтелгән гаризаны кире кагу өчен нигезләр ачыкланган очракта, гариза конкурста катнашудан төшеп кала.

6.3. Конкурста катнашуга кертелгән дәгъва кылучыларга анкетада күрсәтелгән телефон номеры буенча көндезге этапның урыны һәм вакыты турында 5 календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

6.4. Премиягә дәгъва кылучылар үз проектларын көндезге яклау барышында тәкъдим итә. Чыгыш вакыты – 10 минутка кадәр, конкурс комиссиясе сорауларына җаваплар – 5 минутка кадәр.

6.5. Конкурс 2025 елның 10 апреленнән 18 апреленә кадәр үткәрелә.

6.6. Конкурсның һәр катнашучысы буенча бәя һәрберсенә аерым куела һәм Конкурс комиссиясе әгъзасының шәхси бәяләү битендә куела.

6.7. Бәяләү кәгазе конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан әлеге Нигезләмәгә 2 номерлы кушымта нигезендә тутырыла һәм комиссия беркетмәсе белән раслана.

6.8. Бәяләү кәгазенең һәр критерие, конкурс комиссиясе әгъзасының ихтыяры буенча, 1 дән 5 баллга кадәр бәяләнә.

6.9. Катнашучының рейтингы Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасына тигез.

6.10. Конкурс йомгаклары турында конкурс комиссиясе карары күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм конкурс уздырылган көннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча конкурс комиссиясе рәисе раслаган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Конкурс комиссиясе әгъзасы, Конкурс нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, беркетмәгә үзенең аерым фикерен кертә.

6.11. Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе 2025 елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарының рәсми порталы яңалыклар бүлегендә конкурс нәтиҗәләрен бастырып чыгара (https://kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/upravlenie-sotsialnoy-politiki/novosti/).

## VII. Катнашучыларны бүләкләү

7.1. Конкурсның һәр өч номинациясендә җиңүче, көмеш һәм бронза призерлар билгеләнә. Призерлар һәм җиңүчеләр санына эләкмәгән катнашучылар Конкурста катнашу турында грамоталар белән билгеләп үтеләчәк.

7.2. Һәр өч номинациянең һәркайсында бирелә торган премия күләме:

- конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча 1 урын алган катнашучыга – 250,0 мең сум;
- конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча 2 урын алган катнашучыга – 150,0 мең сум;
- конкурста сайлап алу нәтиҗәләре буенча 3 урын алган катнашучыга – 100,0 мең сум.

7.3. Премия бирү турындагы карарны конкурс комиссиясе экспертиза нәтиҗәләре буенча гади күпчелек тавыш белән кабул итә. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда расланган составның кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы дип санала.

7.4. Конкурста бүләкләү һәм аңа йомгак ясау өчен барлык конкурсантлар чакырыла. Конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү 2025 елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча уздырылачак. Бүләкләү уздыруның урыны һәм вакыты турында мөрәҗәгать итүчеләргә анкетада күрсәтелгән телефон номеры буенча өстәмә рәвештә биш календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

7.5. Премияне түләү өчен нигез булып, комиссия беркетмәсе һәм премия алучының хисап реквизитлары күрсәтелгән гаризасы тора.

7.6. Акчалата премия алу өчен җиңүче һәм призерлар, үзләрен җиңүче дип таныганнан соң 1 (бер) айдан да соңга калмыйча, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе белән (social.kzn@tatar.ru) электрон почта аша элемтәгә керергә һәм акчалата премия алу өчен кредит оешмасында ачылган, акча премиясе күчерелергә тиешле счетларның реквизитлары турында белешмәләр булган акча премиясен күчерү турындагы гариза бирергә тиешләр. Гариза Конкурста җиңүче (призер) тарафыннан имзаланырга тиеш.

7.7. Гариза тәкъдим ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә карала.

7.8. Конкурста җиңүчегә һәм призерларга премия 2025 елның 31 декабренә кадәр берьюлы бирелә.

7.9. Игълан иткән вакыттан соң бер ай вакыт узгач Конкурста җиңүченең (призерның) акчалата премияне сорап алмавы мондый җиңүчене (призерны) акчалата премия алу хокукыннан мәхрүм итә.

7.10. Конкурста җиңүчегә һәм призерларга билгеләнгән үрнәктәге дипломнар тапшырыла.

Социаль юнәлешле коммерциягә
нигезләнмәгән оешмалар
арасында Казан шәһәре Мэры
премиясенә «Игелекле эшләр
шәһәре» конкурсы турында
Нигезләмәгә 1 номерлы кушымта
(Форма)

(Оешма бланкында рәсмиләштерелә)

**Социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар арасында Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсында катнашу өчен гариза**

Гаризаны карауны сорыйм

______________________________________________________________

(оешма атамасы)

Социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар арасында Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсында катнашу өчен гариза.

Әлеге гариза белән гариза нигезендә сайлап алуга бәйле мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгымны белдерәм.

Гариза бирү көненә оешма ябылу яисә үзгәртеп кору процессында булмавына, шулай ук вәкаләтле органның оешма эшчәнлеген туктатып тору турында гамәлдәге карары булмавына гарантия бирәм.

Кушымталар: 1. Оешманың ___ битлек ___ нөсхәдәге мәгълүмати картасы.

2. Проектның/проектларның ___ битлек ___ нөсхәдәге мәгълүмати картасы/мәгълүмати карталары.

3. Проектны гамәлгә ашыруга киткән чыгымнар турында ___ битлек ___ нөсхәдәге хисап (документ күчермәләрен беркетеп).

4. Оешма уставының ___ битлек ___ нөсхәдәге таныкланган күчермәсе.

5. Оешма җитәкчесенең вәкаләтләрен раслаучы документлар.

6. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

7. Салым органыннан соңгы хисап датасына оешманың барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлар һәм бюджеттан тыш фондлар алдында түләү вакыты узган бурычы булмавын раслый торган белешмә.

8. Электрон чыганакта (флеш-карта) гаризаның күчермәсе.

| ____________________ | ____________ | ____________ |
|---|---|---|
| (оешма җитәкчесе вазифасының атамасы) | (имза) | (Инициаллар һәм фамилия) |

Мөһер урыны

____________
(дата)

Социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар арасында Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсында катнашу өчен гаризага 1 номерлы кушымта
(Форма)

**Оешманың мәгълүмати картасы**

| | |
|---|---|
| 1. Оешманың тулы исеме | |
| 2. Оешманың кыскартылган исеме | |
| 3. Тәкъдим ителгән проектның исеме (тәкъдим ителгән проектлар исемлеге) | |
| 4. Оешманың оештыру-хокукый формасы | |
| 5. Оешманың реквизитлары | - |
| Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) | |
| Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| Исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) | |
| Икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД) | |
| 6. Җәмәгать файдалы хезмәт күрсәтүләрен башкаручы итеп оешманың реестр номеры һәм аны тану датасы (оешма коммерцияле булмаган оешма – иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүләрне башкаручы статусына ия булса) | |
| 7. Элемтә өчен мәгълүмат | - |
| юридик адрес (почта индексы белән) | |
| телефон (торак пункт коды белән) | |
| электрон почта | |
| веб-сайт (булган очракта) | |
| 8. Оешманың банк реквизитлары | - |
| банкның атамасы | |
| банкның урнашу урыны (почта индексы белән) | |
| Банкның тәңгәлләштерү номеры (ИНН)/исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) | |
| корреспондент счеты | |
| Банкның тәңгәлләштерү коды (БКК) | |

| | |
|---|---|
| исәп-хисап счеты | |
| 9. Оешма җитәкчесе | - |
| фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| җитәкче вазифасы (устав нигезендә) | |
| 10. Устав нигезендә оешма эшчәнлегенең төп максатлары (өчтән дә артык түгел) | |
| 11. Оешма эшчәнлеге юнәлдерелгән төп максатчан төркемнәр (өчтән дә артык түгел) | |
| 12. Соңгы ике елда алынган муниципаль субсидияләр турында белешмәләр (субсидия алу елы, субсидия суммасы, проектның исеме) | |
| 13. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар белән хезмәттәшлек тәҗрибәсе | |
| 14. Соңгы ике елда уңышлы гамәлгә ашырылган өчтән дә артмаган проектларның кыскача тасвирламасы (проектның исемен, төп максатларны, проектның бюджетын, финанслау чыганакларын, ирешелгән нәтиҗәләрне күрсәтергә) | |
| 15. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (бастырылган материалга сылтамаларны күрсәтергә), массакүләм мәгълүмат чараларында (массакүләм мәгълүмат чарасын һәм материалның басмага, эфирга чыгу вакытын күрсәтергә) оешманың эшчәнлеге турында мәгълүмат булу | |

______________________________ ______________ ______________________

(оешма җитәкчесе вазифасының атамасы) (имза) (Инициаллар һәм фамилия)

Мөһер урыны

______________________

(дата)

Социаль юнәлешле
коммерциягә нигезләнмәгән
оешмалар арасында Казан
шәһәре Мэры премиясенә
«Игелекле эшләр шәһәре»
конкурсында катнашу өчен
гаризага 2 номерлы кушымта
(Форма)

**Проектның мәгълүмати картасы**

| | |
|---|---|
| 1. Конкурс номинациясе | |
| 2. Социаль әһәмияткә ия проект исеме | (иң күбе 300 символ) |
| 3. Социаль әһәмияткә ия проектның тасвирламасы (резюме) | |
| 4. Социаль әһәмияткә ия проектны гамәлгә ашыра башлау | (ай, ел) |
| 5. Социаль әһәмияткә ия проектны гамәлгә ашыруны тәмамлау | (ай, ел) |
| 6. Проблемасын һәм социаль әһәмиятен нигезләү | |
| 7. Социаль әһәмияткә ия проектның максатчан төркемнәре | |
| 8. Социаль әһәмияткә ия проектның максаты | |
| 9. Социаль әһәмияткә ия проектның бурычлары | 1.<br>2. |

<table>
<tr><td>10. Социаль әһәмиятле проект командасы</td><td colspan="3">Фамилиясен, исемен, атасының исемен күрсәтергә; эш урынын; проектта катнашучыларның вазифасын; квалификация булуны раслаучы документлар (кирәк булганда); катнашу характеры (хезмәткәр, граждан-хокукый характердагы килешү, хат-ризалык, телдән килешү)</td></tr>
<tr><td rowspan="4">11. Социаль әһәмияткә ия проектның партнерлары</td><td>Партнер</td><td>Ярдәм төре</td><td>Нигез</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>килешү яисә шартнамә</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>хат</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td>башка</td></tr>
<tr><td>12. Сыйфат нәтиҗәләре</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td rowspan="2">13. Җитештерү нәтиҗәләре</td><td colspan="2">Күрсәткеч</td><td>Күрсәткечнең план әһәмияте</td></tr>
<tr><td colspan="2"></td><td></td></tr>
<tr><td>14. Проектны гамәлгә ашыруның фото-, видеоматериаллары</td><td colspan="3">Материалларга сылтама беркетеп куела</td></tr>
<tr><td>15. Проектны мәгълүмати яктан тәэмин итү</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>16. Социаль әһәмияткә ия проектның алга таба үсеше</td><td colspan="3">Алдагы елларда гамәлгә ашыру өчен планлаштырыла торган чаралар күрсәтелә</td></tr>
<tr><td>17. Социаль әһәмияткә ия проектны ресурслар белән тәэмин итү чыганаклары</td><td colspan="3"></td></tr>
</table>

____________________________ ______________ __________________
(оешма җитәкчесе вазифасының атамасы) (имза) (Инициаллар һәм фамилия)

Мөһер урыны

Социаль юнәлешле
коммерциягә нигезләнмәгән
оешмалар арасында Казан
шәһәре Мэры премиясенә
«Игелекле эшләр шәһәре»
конкурсында катнашу өчен
гаризага 3 номерлы кушымта
(Форма)

**Социаль әһәмияткә ия проектның мәгълүмати картасы**

| **№ т/б** | **Эшчәнлек юнәлеше** | **Чара** | **Башлану** | **Тәмамлану** | **Йомгаклар (микъдар һәм сыйфат күрсәткечләре белән)** |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

Социаль юнәлешле
коммерциягә нигезләнмәгән
оешмалар арасында Казан
шәһәре Мэры премиясенә
«Игелекле эшләр шәһәре»
конкурсы турында Нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(Форма)

**Урында эшләү этабының бәяләү кәгазе**

Конкурста катнашучы__________________________________________________

(оешманың атамасы)

________номерлы гариза тәкъдим итүче

__________________________________________________________

(проектның исеме)

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәя (1 дән 5 баллга кадәр) | Ачыклама |
|---|---|---|---|
| 1 | Социаль әһәмияткә ия проектның игълан ителгән номинациягә һәм әлеге Нигезләмәнең таләпләренә туры килүе | | |
| 2 | Социаль әһәмияткә ия проектның оригинальлеге дәрәҗәсе, аның креатив һәм инновацион характеры | | |
| 3 | Җәмгыятьнең социаль әһәмиятле проблемаларын хәл итү чараларының проектта эшкәртелү дәрәҗәсе | | |
| 4 | Социаль әһәмиятле проектның ахыргы нәтиҗәләренең актуальлеге дәрәҗәсе, аны гамәлдә куллануның максатчанлыгы, Казан шәһәренең социаль үсеше өчен проектның югары социаль һәм иҗтимагый әһәмияте | | |

| **№ т/б** | **Бәяләү критерие** | **Бәя (1 дән 5 баллга кадәр)** | **Ачыклама** |
|---|---|---|---|
| 5 | Социаль әһәмияткә ия проектның икътисадый максатка ярашлылыгы дәрәҗәсе һәм аның нәтиҗәлелеге (чыгымнар һәм планлаштырыла торган нәтиҗә нисбәте), өстәмә акчалар җәлеп итү мөмкинлеге | | |
| 6 | Сорауларга җаваплар | | |
| **Бәяләрнең йомгаклау суммасы** | | | |

________________________________________ ________________________________________

(Комиссия әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имза)

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 13 февралендәге
365 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар арасында Казан шәһәре Мэры премиясенә «Игелекле эшләр шәһәре» конкурсы җиңүчесен һәм призерларын билгеләү буенча конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Г.Р.Сәгыйтова | комиссия рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| И.П.Смирнова | комиссия рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе башлыгы |
| Ф.В.Гринь | комиссия сәркатибе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе социаль проектлар бүлеге баш белгече |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| В.И.Яковлев | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе урынбасары – хокук идарәсе башлыгы |
| Л.З.Гарипов | Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты рәисе |
| А.И.Абзалов | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы |
| А.Р.Заһидуллина | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисе |
| И.А.Ризванов | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы |
| Т.С.Мерзляков | «Игелекле Казан» автоном коммерциягә нигезләнмәгән оешмасы директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| А.Ф.Вәлиева | «Ак Барс «СОЗИДАНИЕ» автоном коммерциягә нигезләнмәгән оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| З.Н.Сафина | «Россия Кызыл Хачы» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| А.Г.Дыганов | Социаль өлкә инновацияләре һәм социаль юнәлештәге коммерциясез оешмалар үзәге җитәкчесе (килешү буенча) |

---